# ДЕМОНСТРАЦИОННЫЕ ЗАДАНИЯ ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНОГО ЭТАПА
## Северо-Восточной олимпиады школьников по родным языкам
## (профиль – «Родной (татарский) язык и литература»)

## 8-9 КЛАССЫ

**1 нче бирем. Задание 1.**

Түбәндәге исемнәрнең гомуми атамасы өчен сүзләр табыгыз. Исемнәрне бер сүз белән берлек санда языгыз. / Найдите слова для общего наименования нижеприведенных существительных. Напишите имена одним словом в единственном числе.

*Үрнәк:*

*Сыйныф, укучы, укытучы – мәктәп.*

1.1. Эне, апа, дәү әти – ... .

1.2. Шәмәхә, күгелҗем, көлсу – … .

1.3. Дәлия, сөмбел, лалә – … .

1.4. Бытбылдык, шәүлегән, сыерчык – … .

**Максимальный балл – 4.**

**Ренат Харисның «Идел өстендә көмеш Ай...» шигырен укыгыз. Бу шигырь тексты буенча 2-5 нче биремнәрне үтәгез. / Прочитайте стихотворение Рената Хариса «Серебряная Луна над Волгой». Выполните задания 2-5 по тексту данного стихотворения.**

**Ренат Харис. Идел өстендә көмеш Ай...**

Идел өстендә көмеш Ай
эленгән – китми, бармый,
дымлы комда көмешләнә
акчарлак койган каурый.

Идел суы зәңгәр төнне
ахыргача сеңдергән.
Дулкыннар иренеп кенә
йолдызларны сүндерә.

Мин торам салкын балконда,
ә өйдә җылы-җылы...
Ак түшәктә ауный-ауный,
минем шигырем җылый —

әйтерсең лә гүзәл хатын!
Минем мендәрне кочкан.
Сөюгә багышланганга,
ул җылый куанычтан.

Идел өстендә тулган Ай
эленгән, һаман тора,
балкон тәрәзеннән кереп,
шигыремне яктырта.

Идел суы акчарлакның
каурые кебек якты...
Мин дә, бер иркәләним дип,
шигырь янына яттым.

**2 нче бирем. Задание 2.**

Шигъри текстның китерелгән өзегеннән беренче өч исем сүз төркеменә караган берәмлекне язып алыгыз һәм сызыктан соң текстта килгән тәртиптә аларның килеш, тартым һәм сан белән төрләнешен күрсәтегез. / Выпишите из приведённого фрагмента поэтического текста три первых имени существительных и напишите после тире их падеж в порядке следования в тексте с полным именованием падежа, принадлежности и числа.

эленгән, һаман тора,
балкон тәрәзеннән кереп,
шигыремне яктырта.

**Максимальный балл – 3.**

**3 нче бирем. Задание 3.**

Грамматик форма нигезендә шигырьнең түбәндәге фрагментыннан фигыльләрне төркемләгез. Һәр төркемдә бу строфадагы барлык фигыльләрне санап чыгарга һәм аларның грамматик үзенчәлекләрен билгеләргә кирәк. Бу төркемнәрдәге фигыльләрне нинди грамматик билге(ләр) аерганын күрсәтегез. / Сгруппируйте глаголы из нижеследующего фрагмента стихотворения на основе грамматической формы. В каждой группе должны быть перечислены все глаголы из этой строфы и определены их грамматические характеристики. Какое (-ие) грамматическое значение (грамматические значения) разъединяет (-ют) эти группы глаголов.

Идел өстендә көмеш Ай
эленгән – китми, бармый,
дымлы комда көмешләнә
акчарлак койган каурый.

**Максимальный балл – 6.**

**4 нче бирем. Задание 4.**

Ренат Харис шигыреннән китерелгән фрагментларда нинди сурәтләү чаралары кулланылган? Аларның исемен үрнәктәгечә сызыктан соң языгыз: / Какие художественно-изобразительные средства использовал Ренат Харис в приведенных фрагментах? Напишите их название через тире по образцу:

*«Әйтерсең лә гүзәл хатын!» – чагыштыру.*

3.1. «Дулкыннар иренеп кенә йолдызларны сүндерә» – …
3.2. «Идел суы акчарлакның каурые кебек якты...» – …
3.3. «Идел өстендә көмеш Ай» – …

**Максимальный балл – 3.**

**5 нче бирем. Задание 5.**

Түбәндәге фрагментта һәрбер җөмләнең төрен билгеләгез, җөмлә кисәкләренә тулы характеристика бирегез. Туган тел кагыйдәләре нигезендә җөмләдәге өтерләрнең куелышын аңлатыгыз. / В приведённом ниже фрагменте из стихотворения определите вид каждого предложения, дайте полную характеристику членам предложений. Прокомментируйте употребление запятых в данном предложении на основе правил родного языка.

Идел суы акчарлакның
кауры кебек якты...
Мин дә, бер иркәләним дип,
шигырь янына яттым.

**Максимальный балл – 10.**

**Фәнис Яруллинның “Кояштагы тап” әкиятен укыгыз. Бу текст буенча 6-8 нче биремнәрне үтәгез. / Прочитайте сказку Фаниса Яруллина «Пятно на солнце». Выполните задания 6-8 по этому тексту.**

Еракта, бик еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәр көн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның әнисе кояш белән бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ә улы аңардан юри генә дә: «Әнием, син көннәр буе ниләр эшлисең?» – дип сорамаган, гел уйнаган да уйнаган.

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе авырып түшәккә егылган. Шунда ул урамда йөрүче улын өенә чакырып керткән дә болай дигән:

— Улым, үзең күрәсең, хәлем кинәт начарланып китте. Хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик-бик эчәсем килә. Иреннәрем кара көеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым, – дигән әнисе аңарга, – суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай чиләген күтәреп урамга чыккан. «Мондый кызуда шултиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле», – дип уйлаган малай һәм өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең дә бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

Менә ул бермәлне тирләп-пешеп судан кайтып кергән. Әнисе аның чәчләреннән сыйпап: «Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт», – дигән. Һәм йотлыгып-йотлыгып суны эчә башлаган. Эчкән саен күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп җиткән. Малай сөенә-сөенә урамга чыгып йөгергән.

«Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде», – дип уйлаган ул. Шулай дип уйлавы булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар куркышып ояларыннан качканнар. Шомлы итеп, елап-елап этләр өрергә тотынган. Малай ни уйларга да белмичә, курка-курка өенә чапкан.

— Әни, – дигән ул, сулышын көчкә-көчкә алып, – нишләптер кояшның йөзе каралды. Әнә тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

— Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

— Әни, – дигән малай, башын түбән иеп, – мин суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шул вакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

*Фәнис Яруллиннан*

**6 нчы бирем. Задание 6.**

Әлеге текстан “дөнья читендә” мәгънәсен аңлатмый торган ялгызлык исемне язып алыгыз. Сүзтезмә компонентларының кайсы сүз төркеменә каравын һәм алар арасындагы бәйләнешнең төрен билгеләгез. / Выпишите из текста собственное имя, которое не выражает значение «на краю света». Укажите, какими частями речи выражены компоненты словосочетания. Определите, каким видом синтаксической связи они объединены.

**Максимальный балл – 3.**

**7 нче бирем. Задание 7.**

*Яманлыкны* һәм *икәнлеген* сүзләрен сүз составы ягыннан тикшерегез. Аларның морфемалар составы туры киләме? Уңай яки тискәре җавап бирегез һәм җавабыгызны дәлилләгез. Әлеге сүз ясалышы тибы буенча ясалган 2 мисал китерегез.

Разберите по составу слова из вышеприведенного текста: *яманлыкны* и *икәнлеген*. Совпадает ли их морфемный состав? Ответьте утвердительно или отрицательно и поясните свой ответ. Приведите два примера слов с таким(-и) же типом словообразвания, что и в словах *яманлыкны* и *икәнлеген*.

**Максимальный балл – 5.**

**8 нче бирем. Задание 8.**

Текстта кулланылган *өрергә, кояш, уйлавы* сүзләрендәге хәреф һәм аваз санын билгеләгез. Аермалар булган очракта, сәбәбен аңлатыгыз. / Определите количество букв и звуков в словах *өрергә, кояш, уйлавы* из вышеприведенного текста. В случае наличия буквенно-звукового расхождения объясните причину.

**Максимальный балл – 6.**

**9 нчы бирем. Задание 9.**

Текстны рус теленнән татар теленә тәрҗемә итегез. Тәрҗемә ителгән һәр җөмләдә эчтәлекне тапшыруның адекватлыгына һәм фикер формасын дөрес сайлауга аеруча игътибар бирегез. / Переведите текст с русского языка на татарский. Обратите особое внимание на адекватность передачи содержания и правильность выбора формы выражения мысли в каждом переведенном предложении.

КОШКА И МЫШКА

В одном селе, на самой окраине, стоял небольшой домик. В нем жили старик со старухой, кошка Мурка и мышка Пика. Мышка с кошкой жили дружно и весело, всегда помогали друг другу. Иногда хозяйка забывала покормить Мурку, тогда Пика приносила подруге сухарик или кусочек сыра. Когда у Пики заканчивалась еда, Мурка ее тоже выручала. Она ходила вокруг хозяйки, пока та варила. Хозяйка вначале ругалась, а потом угощала любимицу. А кошка сама не ела, мышке еду относила. Так они и жили, пока в один весенний день не случилось несчастье. Мурка гуляла на улице и съела видимо, что-то не то. Вечером ей стало очень плохо. Она лежала на полу и сильно мяукала. Когда мышка попыталась дотронуться до живота подруги, чтобы пожалеть, та зашипела и выпустила когти. Пика направилась в лес, где взяла у дальней родственницы, старой и мудрой мыши, траву и дала ее кошке. Утром Мурка выздоровела и подруги еще больше сблизились.

**Максимальный балл – 30.**

**10 нчы бирем. Задание 10.**

Үзегез теләгән бер хикәягә тәкъдим ителгән план нигезендә анализ ясагыз. Сезнең 150-200 сүз күләмендәге җавабыгыз тулы, төгәл, эзлекле һәм бөтенлекле булырга тиеш. Иң югары балл – 30. / Выполните анализ прозаического произведения на татарском языке по предложенному плану. Ваша работа должна представлять собой цельный, связный, завершённый текст. Рекомендуемый объём – 150–200 слов. Максимальный балл – 30.

1. Хикәянең темасын һәм идеясен, анда күтәрелгән проблемаларны ачыклап языгыз (язучы нәрсә әйтергә тели, үз фикерен ничек җиткерә һ.б.).

*Определите тему и идею данного произведения, проблемы, затронутые в нём (что хотел сказать автор и как ему удалось это сделать?).*

2. Хикәядә төп сюжет элементларын билгеләгез (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминацион нокта, чишелеш).

*Определите основные элементы сюжетной линии рассказа (экспозиция, завязка, развитие действия, кульминация, развязка).*

3. Хикәядә катнашкан геройларны төп, ярдәмче, эпизодик кебек төркемчәләргә аерып языгыз һәм аларга характеристика бирегез: характерлары, үзара аралашу үзенчәлеге, персонажларның типиклыгы яки уникальлеге, портретлары (төс-кыяфәтләре, киемнәре һ.б.).

*Разделите образы персонажей рассказа (главные, второстепенные или эпизодические образы) и дайте им характеристику: характеры, взаимоотношения между персонажами, типичность или уникальность персонажей, своеобразие созданного образа человека: портрет (лицо, фигура, костюм).*

4. Хикәядә нинди тел-сурәтләү чаралары һәм әдәби алымнар кулланыла? Әсәрдә алар нинди функция үтиләр, язучы аларны нинди максатлардан чыгып файдалана?

*Какие художественные средства и приёмы создают особый эмоциональный фон рассказа? И какую функцию они выполняют в произведении?*

5. Хикәягә, андагы вакыйгаларга, геройларга карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (хикәя сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?).

*Выразите свое эмоционально-оценочное отношение к прочитанному (Какие чувства и эмоции вызывает рассказ? О чем заставляет задуматься?).*

**Тулаем эш (1-10нчы биремнәр) 100 балл белән бәяләнә.**
**Максимальный балл за всю работу (задания 1-10) – 100**

## Бәяләү системасы һәм критерийлар

## Система и критерии оценивания

| № задания | Правильные ответы | Критерии оценивания | Максимальное кол-во баллов |
|---|---|---|---|
| **Задание 1.** | 1.1. ГАИЛӘ / ТУГАН<br>1.2. ТӨС<br>1.3. ЧӘЧӘК | За нахождение правильного общего именования (родового понятия в виде собирательного | **4 балла** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1.4. КОШ | существительного) для четырех видовых понятий дается **1 балл**. В случае нахождения неправильного общего наименования или отсутствия его в сданной работе учащийся получает 0 баллов. | |
| **Задание 2.** | *Балкон* – исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә.<br>*Тәрәзеннән* – исем, берлек санда, 3 зат тартым белән төрләнгән, чыгыш килешендә.<br>*Шигыремне* – исем, берлек санда, 1 зат тартым белән төрләнгән, төшем килешендә. | **0,5 балла –** за правильно определенную часть речи (существительное);<br>**0,5 балла** – за верно определенные падеж, число и принадлежность. | **3 балла** |
| **Задание 3.** | *1. Еленгән, көмешләнә, койган* – фигыльләр; *еленгән* – билгесез (нәтиҗәле) үткән заман хикәя фигыль, затланышлы, 3 зат берлектә, барлыкта, төшем юнәлешендә, җөмләдә хәбәр.<br>*көмешләнә* – хәзерге заман хикәя фигыль, затланышлы, 3 зат берлектә, барлыкта, төшем юнәлешендә, җөмләдә хәбәр.<br>*койган* – үткән заман сыйфат фигыль, затланышсыз, төп юнәлештә, җөмләдә хәбәр.<br>*2. Китми, бармый* – фигыльләр; хәзерге заман хикәя фигыльләр, затланышлы, 3 зат берлектә, төп юнәлештә, юклыкта, җөмләдә аныклагыч булып килгәннәр.<br><br>Әлеге төркемнәрдәге фигыльләрне аера торган билге булып барлык-юклык формалары тора. | **2 балла** – за правильно составленные группы.<br>**2 балла** – за правильное определение грамматических значений в обеих группах.<br>**2 балла** – за правильную формулировку дифференциального признака в обеих группах (грамматического значения, разъединяющего группы). | **6 баллов** |
| **Задание 4.** | 3.1. «Дулкыннар иренеп кенә йолдызларны сүндерә» – җанландыру (сынландыру).<br>3.2. «Идел суы акчарлакның каурые кебек якты...» – чагыштыру.<br>3.3. «Идел өстендә көмеш Ай» – эпитет. | **1 балл** – за каждое правильно указанное средство выразительности. | **3 балла** |
| **Задание 5.** | *Идел суы акчарлакның каурые кебек якты... Мин дә, бер иркәләним дип, шигырь янына яттым.*<br>Бу – тезмә кушма җөмлә.<br>Беренче җөмлә – *Идел суы акчарлакның каурые кебек якты...* | **1 балл** – за правильное определение вида сложного предложения, указание отдельных предложений и средства связи;<br><br>**8 баллов** – за верное | **10 баллов** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Икенче җөмлә – <u>*Мин*</u> *дә, бер иркәләним дип, шигырь янына* <u>*яттым*</u>. Ике җөмлә үзара ***дә*** тезүче (җыючы) теркәгече ярдәмендә бәйләнгән.<br>Ике җөмлә дә – ике составлы, тулы, җәенке, хикәя, раслаулы, гадәти җөмләләр.<br>*Суы* – ия, гади ия, исем белән белдерелгән, берлек санда, 3 зат тартым белән төрләнгән, баш килештә. **1 б.**<br>*Якты* – хәбәр, гади исем хәбәр, сыйфат белән белдерелгән. **0,5 б.**<br>*Идел* (суы) – аергыч, ялгызлык исем белән белдерелгән, берлек санда, баш килештә. **1 б.**<br>*Акчарлакның* (каурые) – аергыч, исем белән белдерелгән, берлек санда, иялек килешендә. **1 б.**<br>*Каурые кебек* (якты) – күләм хәле, 3 зат тартым белән төрләнгән, берлек санда, баш килештәге исем һәм бәйлек белән белдерелгән. **1 б.**<br><br>*Мин* – ия, гади ия, зат алмашлыгы белән белдерелгән. – **0,5 б.**<br>*Яттым* – хәбәр, гади фигыль хәбәр, билгеле үткән заман хикәя фигыль белән белдерелгән, 1 зат берлектә. **1 б.**<br>*Бер иркәләним дип* (яттым) – аерымланган максат хәле, микъдар саны, 1 зат берлектәге теләк фигыль һәм бәйлек сүз белән белдерелгән. **1 б.**<br>*Шигырь янына* (яттым) – урын хәле, берлек сан, баш килештәге исем һәм бәйлек сүз белән белдерелгән. **1 б.**<br><br>Максат хәле җөмләдәге үзе ияреп килгән кисәктән (яттым) ераклашкан, шуңа күрә ике яктан өтер белән аерымланган. | определение и характеристику каждого члена предложения.<br><br>**1 балл** – за верное объяснение запятых. | |
| **Задание 6.** | *Көймә тавы.*<br>Исемле исем сүзтезмә,<br>ияртүче сүз – тавы, берлек санда, 3 зат тартым белән төрләнгән, баш килештәге исем белән белдерелгән;<br>иярүче сүз – көймә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештәге исем белән белдерелгән. | **1 балл** – за верно указанное собственное имя.<br>**1 балл** – за правильное определение структуры устойчивого словосочетания.<br>**1 балл** – за верное определение синтаксической связи. | **3 балла** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Алар арасындагы бәйләнеш төре – ияртүле бәйләнешнең ачыклаулы төре. | | |
| **Задание 7.** | Яман-лык-ны<br>Икән-лег-е-н<br>Бу сүзләрнең морфемалар составы бер түгел.<br>Яманлыкны (яман – сыйфат, -лык – исем ясагыч кушымча, -ны – төшем килеше кушымчасы);<br>Икән-лег-е-н (икән – хәбәрлек сүз, -лек – исем ясагыч кушымча, -е – 3 зат берлек сандагы тартым кушымчасы, -н – төшем килеше кушымчасы)<br><br>Мондый төрдә ясалган сүзләр:<br>Сафлык – сафлыкны, сафлыгын.<br>Тиешлек – тиешлекне, тиешлеген. | **1 балл** – за правильный разбор слова с использованием общепринятых знаков для обозначения морфем (по 1 баллу за каждое слово).<br>**1 балл** – за верное объяснение сходства или различия в составе слов.<br>**2 балла** – за два верно приведённых примера (по 1 баллу за каждый пример). | **5 баллов** |
| **Задание 8.** | *Өрергә, кояш, уйлавы*<br><br>*Өрергә* [өрөргә]<br>Әлеге сүздә 6 хәреф, 6 аваз, әмма әйтелеш һәм язылыш арасында аерма күзәтелә, чөнки әйтелештә сингармонизм законының ирен гармониясе чагыла.<br><br>*Кояш* [қойаш]<br>Әлеге сүздә 4 хәреф, 5 аваз,<br>Хәреф һәм авазлар саны арасында аерма күзәтелә, чөнки 1) я хәрефе ике авазга билге булып йөри; 2) к хәрефе увуляр қ авазын белдерә.<br><br>*Уйлавы* [уйлаwы]<br>6 хәреф, 6 аваз, әмма язылыш һәм әйтелеш арасында аерма бар: ирен-теш в хәрефе ирен-ирен w авазына билге булып йөри. | **3 балла** – за правильное определение количества букв и звуков (по 1 баллу за каждый правильный ответ);<br>**3 балла** – за верное объяснение расхождения в буквах и звуках (по 1 баллу за каждый правильный ответ). | **6 баллов** |
| **Задание 9.** | МӘЧЕ БЕЛӘН ТЫЧКАН<br>Бер авылның иң читендә / кырыенда кечерәк кенә / зур булмаган бер йорт тора. Анда карт белән карчык, Мурка исемле мәче һәм тычкан Пика яши. Тычкан белән мәче дус-тату һәм күңелле гомер итәләр, бер-берсенә булышалар. Кайвакыт хуҗабикә Мурканы ашатырга оныта, шул вакытта Пика дустына сохари яки сыр кисәге | Каждое из 11 переведенных предложений текста оценивается по двум критериям, предполагающим получение конкретного количества баллов:<br>**1 балл** – адекватная передача содержания предложения из текста оригинала средствами языка перевода.<br>**0 баллов** – в случае наличия серьезного отклонения от | **30 баллов** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | китерә. Пиканың ашарына беткәч, Мурка да аңа булыша. Хуҗабикә ашарга пешергәндә, мәче аның тирәсендә йөри. Хуҗабикә башта ачулана, ә аннары яратканын сыйлый. Ә мәче үзе ашамый, тычканга илтә. Язгы бер көндә бәхетсезлеккә очраганчы, алар шулай яшиләр. Мурка урамда йөри һәм ниндидер ярамаган әйбер ашый булса кирәк. Кич белән аның хәле бик нык начарлана. Ул идәндә ята һәм каты итеп мияулый. Тычкан, дустын кызганып, корсагына кагылырга теләгәч, тегесе ысылдый башлый һәм тырнакларын чыгара. Пика урманга китә, анда ул ерак туганы карт һәм зирәк тычканнан үлән ала һәм аны мәчегә бирә. Иртән Мурка терелә һәм дуслар тагын да якынаялар. | содержания оригинала или неадекватной передачи содержания;<br>**1 балл** – выбор правильной формы передачи мысли в предложении на языке перевода (грамотное изложение, отсутствие ошибок).<br>**0 баллов** – при неправильном выборе формы выражения мысли в предложении на языке перевода (наличии ошибок, допущении неточностей в формулировках на родном языке).<br>**0 баллов** – при непереведенном предложении. | |
| **Задание 10.** | 1) Хикәянең темасын һәм идеясен, анда күтәрелгән проблемаларны ачыклап языгыз (язучы нәрсә әйтергә тели, үз фикерен ничек җиткерә һ.б.).<br><br>Определите тему и идею данного произведения, проблемы, затронутые в нём (что хотел сказать автор и как ему удалось это сделать?). | 1) **6 балл** – укучы хикәянең темасын, идеясен, проблематикасын дөрес билгели. Үз фикерен төгәл һәм ачык итеп җиткерә.<br>**6 баллов** – учащийся верно определяет тему, идею и проблематику произведения. Четко и ясно выражает свое мнение.<br><br>**4 балл** – укучы хикәянең темасын һәм проблематикасын дөрес билгели, әмма идеясен ачыклый алмый.<br>4 балла – учащийся верно определяет тему и проблематику рассказа, но не смог определить идею произведения.<br><br>**0 балл** – укучы хикәянең темасын, проблематикасын һәм идеясен билгели алмый.<br>0 баллов – учащийся не может определить тему и идею произведения. | **30 баллов** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2) Хикәядә төп сюжет элементларын билгеләгез (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминацион нокта, чишелеш).<br><br>Определите основные элементы сюжетной линии рассказа (экспозиция, завязка, развитие действия, кульминация, развязка). | 2) **6 балл** – сюжет схемасын билгеләүдә хаталар юк. Укучы терминологик аппаратны аңлап-белеп куллана. Сөйләм төгәлсезлекләре һәм стиль хаталары күзәтелми. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы файдаланыла.<br>**6 баллов** – логических ошибок в определении сюжетной схемы нет. Учащийся владеет литературоведческими понятиями и терминами. Речевые и стилистические ошибки отсутствуют. Цитаты и отсылки к тексту уместны.<br><br>**4 балл** – сюжет схемасын билгеләүдә хата бар, бер логик хата урын ала. Җавап эзлекле, цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы кулланыла.<br>**4 балла** – допущена одна логическая ошибка, имеется одно нарушение событийной линии произведения. Речь выразительна и разнообразна. Цитаты и отсылки к тексту уместны.<br><br>**2 балл** – сюжет схемасын билгеләүдә бердән артык хата җибәрелгән, бер логик хата урын ала. Теоретик төшенчәләрнең кулланылышында аерым төгәлсезлекләр күзәтелә. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар һәрвакытта да урынлы кулланылмый.<br>**2 балла** – допущено более одной логической ошибки, Учащийся допускает ошибки в использовании литературоведческих понятий. Цитаты и отсылки к тексту не всегда уместны.<br><br>**0 балл** – сюжет линиясе дөрес анализланмый. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 0 баллов – основные элементы сюжетной линии не определены и не описаны. | |
| | 3) Хикәядә катнашкан геройларны төп, ярдәмче, эпизодик кебек төркемчәләргә аерып языгыз һәм аларга характеристика бирегез: характерлары, үзара аралашу үзенчәлеге, персонажларның типиклыгы яки уникальлеге, портретлары (төс-кыяфәтләре, киемнәре һ.б.).<br><br>Разделите образы персонажей рассказа (главные, второстепенные или эпизодические образы) и дайте им характеристику: характеры, взаимоотношения между персонажами, типичность или уникальность персонажей, своеобразие созданного образа человека: портрет (лицо, фигура, костюм). | 3) **6 балл** – геройларга тулы, дөрес характеристика бирелә, аларның үзенчәлекләре тулы ачыла, төркемчәләре дөрес билгеләнә. Җавапта сөйләм хаталары күзәтелми. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы кулланыла**.**<br>**6 баллов** – дается достаточно полная характеристика героев, своеобразие их образов, особенности взаимоотношений раскрыты достаточно полно. Речевые ошибки отсутствуют. Цитаты и отсылки к тексту уместны**.**<br><br>**4 балл** – геройларга шактый тулы характеристика бирелә, аларның үзенчәлекләре ачыклана, төркемчәләре дөрес билгеләнә. Җавапта сөйләм хатасы күзәтелә. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы кулланыла**.**<br>**4 балла** – дается достаточно полная характеристика героев, своеобразие их образов, особенности взаимоотношений раскрыты достаточно полно. Допущена речевая ошибка. Цитаты и отсылки к тексту уместны.<br>**2 балл** – төп геройларга характеристика гомуми генә бирелә, аларның үзенчәлекләре тулысынча ачыкланып бетми, төркемчәләрен билгеләүдә төгәлсезлекләр урын ала. Җавапта сөйләм хаталары күзәтелә.<br>**2 балла** – характеристика действующих лиц слишком общая, характер взаимоотношений между | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | героями прозаического произведения раскрыт недостаточно. Наличествуют речевые ошибки.<br><br>**0 балл** – төп геройларга дөрес характеристика бирелми. Җавапта сөйләм хаталары еш очрый.<br>**0 баллов** – образы действующих лиц (главных) и взаимоотношения между героями вообще не описаны или описаны с большим количеством речевых ошибок. | |
| | 4) Хикәядә нинди тел-сурәтләү чаралары һәм әдәби алымнар кулланыла? Әсәрдә алар нинди функция үтиләр, язучы аларны нинди максатлардан чыгып файдалана?<br><br>Какие художественные средства и приёмы создают особый эмоциональный фон рассказа? И какую функцию они выполняют в произведении? | 4) **6 балл** – укучы хикәядә кулланылган тел-сурәтләү чараларын һәм әдәби алымнарны дөрес билгели, аларның әсәрдә нинди функция үтәвен, язучының аларны нинди максатлардан чыгып файдалануын хаталарсыз аңлата. Теоретик төшенчәләрне аңлап-белеп куллана.<br>**6 баллов** – учащийся демонстрирует умение объяснить роль художественных средств в раскрытии идейно-эстетического содержания произведения и создании особого эмоционального фона рассказа. Учащийся владеет навыками использования литературоведческих понятий и терминов.<br><br>**4 балл** – укучы хикәядә кулланылган тел-сурәтләү чараларын һәм әдәби алымнарны дөрес билгели, әмма аларның әсәрдә нинди функция үтәвен, язучының аларны нинди максатлардан чыгып файдалануын гомуми генә аңлата. Теоретик төшенчәләрне кулланганда хата күзәтелә.<br>**4 балла** – в работе недостаточно полно раскрыта | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | роль художественных средств в создании эмоционального фона рассказа. Учащийся допустил ошибку в употреблении литературоведческих понятий и терминов.<br><br>**1 балл** – укучы хикәядә кулланылган тел-сурәтләү чараларын һәм әдәби алымнарны билгели, әмма аларның әсәрдә нинди функция үтәвен, язучының аларны нинди максатлардан чыгып файдалануын аңлата алмый. Теоретик төшенчәләр дөрес кулланылмый.<br>**1 балл** – учащийся представил элементы анализа по данному критерию, но не смог объяснить роль художественных средств в раскрытии идейно-эстетического содержания произведения и создании особого эмоционального фона рассказа. Учащийся не владеет литературоведческими понятиями и терминами. | |
| | 5) Хикәягә, андагы вакыйгаларга, геройларга карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (хикәя сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?).<br><br>Выразите свое эмоционально-оценочное отношение к прочитанному (Какие чувства и эмоции вызывает рассказ? О чем заставляет задуматься?). | 5) **6 балл** – укучы хикәягә, андагы вакыйгаларга, геройларга карата үзенең шәхси мөнәсәбәтен тулы һәм дөрес итеп җиткерә ала. Әсәрнең мәгънәсен, автор позициясен дөрес аңлата, сөйләм хаталары күзәтелми.<br>**6 баллов** – учащийся демонстрирует полное понимание смысла произведения, понимание авторской позиции, умение выражать свои мысли, чувства и давать оценку прочитанному, отсутствуют речевые ошибки**.**<br><br>**3 балл** – укучы хикәягә, андагы вакыйгаларга, геройларга карата үзенең шәхси мөнәсәбәтен җиткерә ала. Әсәрнең мәгънәсен, автор | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | позициясен дөрес аңлата, әмма җавапта 1-2 сөйләм хатасы күзәтелә.<br>**3 балла** – учащийся достаточно хорошо понимает текст и умеет выражать эмоционально-оценочное отношение к прочитанному. Допускает одну или две речевые ошибки в содержании ответа.<br><br>**1 балл** – укучы хикәягә, андагы вакыйгаларга, геройларга карата үзенең шәхси мөнәсәбәтен җиткерә алмый. Әсәрнең мәгънәсен, ав **1 балл** – учащийся не совсем понимает смысл произведения. Не может выразить эмоционально-оценочное отношение к прочитанному. | |

**Максимальный балл за всю работу (задания 1-10) – 100**